МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул.Кремлевская, д.9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

Кремль ур., 9 нчы йорт, Казан шәһәре, 420111

Тел.: (843) 294-95-90, факс: (843) 292-93-51, e-mail: Minobr.Priemnaya@tatar.ru, сайт: mon.tatarstan.ru

____________________№________________

На №________________от________________

**Руководителям отделов (управлений) образования исполнительных комитетов муниципальных образований Республики Татарстан**

О проведении XII республиканской научно-практической конференции им.И.Хальфина

**Уважаемые руководители!**

В целях развития творческого потенциала обучающихся, выявления одарённых и талантливых школьников для последующей поддержки и развития их способностей, изучения и популяризации богатого исторического наследия династии Хальфиных, воспитания молодого поколения на примере их жизненного пути и творчества Министерством образования и науки Республики Татарстан совместно с Казанским (Приволжским) федеральным университетом 24 февраля 2017 года проводится XII республиканская научно-практическая конференция, посвященная памяти видного татарского ученого-просветителя Ибрагима Хальфина (далее – Конференция).

В Конференции могут принять участие обучающиеся VIII–XI классов общеобразовательных организаций Республики Татарстан. Для участия в Конференции необходимо направить заявку, тезисы выступления, научно-практические работы в срок до 25 января 2017 года в оргкомитет МБОУ «Гимназия № 14» Авиастроительного района г.Казани по почтовому адресу: 420047, г.Казань, ул.Луначарского, д.9 или на электронный адрес **g.14.halfin@yandex.ru** с пометкой «Конференция» и указанием фамилии автора.

Командировочные расходы производятся за счет направляющей стороны.

Ответственность за жизнь и здоровье школьников в пути следования и во время мероприятия необходимо возложить на сопровождающих педагогов.

Место проведения: МБОУ «Гимназия № 14» Авиастроительного района г.Казани. Адрес проведения: г.Казань, ул.Луначарского, д.9.

Телефоны для справок: (843) 571 62 38, 571 62 48.

Приложение: на 4 л. в 1 экз.

**Заместитель Премьер-министра Республики Татарстан – министр** **Э.Н.Фаттахов**

Л.Р.Зайнуллина
(843) 294 95 10



ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Приложение

**Күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган XII республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясенең**
**НИГЕЗЛӘМӘСЕ**

## I. Гомуми нигезләмә

Әлеге нигезләмә күренекле мәгърифәтче, галим Ибраһим Хәлфин истәлегенә багышланган XII республика фәнни-эзләнү укучылар конференциясен үткәрү тәртибен билгели.

## II. Конференциянең максат һәм бурычлары

2.1. Конференциянең максаты – төрле фәннәр буенча эзләнү эшчәнлеге аша укучыларның иҗади фикер йөртүләрен, интеллектуаль сәләтләрен активлаштыру.

2.2. Конференциянең бурычлары:

хәзерге заман укучысының гомуми һәм коммуникатив культура дәрәҗәсен, социаль активлыгын үстерү һәм җәмгыятьтә үз урынын табарга өйрәтү;

талантлы балаларны барлау, алга таба аларның сәләтләрен үстерүгә мөмкинлекләр тудыру, ярдәм итү;

укучыларның иң яхшы казанышларын, белем бирү оешмаларының фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнү тәҗрибәсен өйрәнү, тәкъдим итү һәм пропагандалау;

тикшеренү эше алып баручы коллективлар белән иҗади багланышлар формалаштыру, үзара аралашу оештыру;

укучыларда милләтнең мәгариф, мәдәният һәм икътисади үсешендә гомерләрен үз халкына хезмәт итүгә багышлаган Хәлфиннәр нәселенең бай тарихи мирасын өйрәнүгә кызыксыну уяту, яшь буынны аларның тормыш юлы һәм иҗаты үрнәгендә тәрбияләү;

милли үзаң, үз милләтеңнең тарихына, мәдәниятына, гореф-гадәтләренә хөрмәт һәм мәхәббәт тәрбияләү.

## III.Конференцияне оештыручылар

Конференцияне оештыручылар:

- Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгы;
- Казан шәһәре башкарма комитеты мәгариф идарәсе;
- Казан (Идел буе) федераль университетының филология һәм мәдәниятара багланышлар институты;

Документ создан в электронной форме. № исх-3271/16 от 14.12.2016. Исполнитель: Зайнуллина Л. Р.
Страница 2 из 6. Страница создана: 12.12.2016 17:51

- Казан шәһәре Авиатөзелеш районының «14 нче гимназия» гомуми белем муниципаль бюджет учреждениесе.

## IV.Бәйгедә катнашучылар

4.1. Конференциядә катнашу өчен мәктәп, гимназия, лицейларның 8 – 11 нче сыйныф укучылары чакырыла.

4.2. Конференциягә аерым укучылар эше, шулай ук 2-3 кешедән торган күмәк эшләр дә кабул ителә.

## V. Конференциянең эш юнәлешләре

Конференция түбәндәге юнәлешләр буенча оештырыла:

- Татар филологиясе проблемалары;
- Рус филологиясе проблемалары;
- Тел белеме һәм сөйләм культурасы (рус, татар һәм чит телләр);
- Туган якны өйрәнү;
- Математика. Физика. Информатика;
- Биология, химия, экология;
- Дөнья мәдәнияте;
- Психология;
- Дөнья цивилизациясе контекстында милли сәнгать, әдәбият һәм мәгариф.

2017 нче елда әлеге секция эше татар киносы тарихына багышлана һәм «Татар киносы: үткәне һәм бүгенгесе» дигән тема буенча эшли.

Әлеге секциянең эш юнәлешләре:

1. Укытучылар өчен «Дәресләрдә татар киносы» темасына иң яхшы дәрес эшкәртмәләре бәйгесе.
2. Укучылар өчен татар киносы тарихына багышланган иң яхшы компьютер презентациясе бәйгесе.

## VI. Фәнни-гамәли эшләргә таләпләр

6.1. Фәнни эш кабул ителгән стандарт кысаларында билгеле бер структурага нигезләнеп үтәлә. Титул бите, эчтәлек, кереш, төп өлеш, йомгак, кулланылган әдәбият исемлеге, кушымта кебек өлешләрдән тора. Фәнни эшнең тексты компьютерда җыелган булырга тиеш. Күләме 15-20 бит. Шрифт Times New Roman – 14. Полялар: сулдан – 30 мм, уңнан – 15 мм, астан һәм өстән – 20 мм. Юл араларында 1,5 интервал кала. Кызыл юл 1см калдырып башлана.

Титул битенә гомуми белем бирү оешмасының тулы исеме, шәһәр, район, укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, сыйныфы, тема, эшнең юнәлеше һәм укытучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме языла.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Кереш, йомгак, әдәбият исемлеге, төп өлешнең аерым бүлекләре яңа биттән башлана.

Кулланылган әдәбият исемлеге яңа юлдан алфавит тәртибендә языла.

Фәнни эш үтә күренмәле тышлы папкага урнаштырылып, 1 данәдә тапшырыла.

6.2. Тезисларны тәкъдим итү тәртибе:

6.2.1. Тезислар Word редакторында А4 форматында 1 интервал белән җыелырга тиеш. Шрифт Times New Roman – 14; өстән, астан, уңнан, сулдан полялар – 2 см. Полялар рамка эченә алынмый.

6.2.2. Тезисларның калыбы түбәндәгечә булырга тиеш:

фәнни-эзләнү эшенең төп фикерләре кыскача чагылыш таба;

тикшерелгән, төзәтүләрсез була;

компьютерда җыела, А4 форматындагы кәгазьнең бер ягына гына сыйфатлы итеп принтерда чыгарылган була;

исеме уртага 14 нче шрифтны калынайтып языла, ахырда нокта куелмый;

авторның исеме, фамилиясе тулаем күрсәтелә, мәктәбе, сыйныфы, фәнни җитәкчесенең фамилиясе 14 нче шрифт белән битнең уң як өлешенә языла;

яңа юлдан башланучы фразалар кызыл юлдан 1 см калдырылып башлана.

Тезис исеме, авторы, фәнни җитәкчесе турындагы мәгълүматлар белән тезис тексты арасындагы ара 1 интервални тәшкил итә.

Тезисларның күләме – 1 бит.

Тезислар электрон варианта тапшырыла.

Конференциягә башка конкурсларда, конференцияләрдә катнашып, призлы урын алган, матбугатта басылган эшләр кабул ителми.

## VII. Бәйгене үткәрү һәм катнашу тәртибе

7.1. Заявка, тезис, фәнни-эзләнү эшләре **2017 нче елның 25 нче гыйнварына кадәр,** авторның фамилиясе күрсәтелеп, **g.14.halfin@yandex.ru** электрон адресына яисә 420047, Казан шәһәре, Авиатөзелеш районы, Луначарский урамы, 9 нчы йортта урнашкан 14 нче гимназия почта адресы буенча кабул ителә. Белешмәләр өчен телефоннар: (843) 571-62-38, 571-62-48.

7.2. 2017 нче елның 26 нчы гыйнварыннан 30 нчы гыйнварына кадәр Конференция читтән торып үтә – килгән эшләр тикшерелә. Килгән эшләрне, оештыру комитеты составына кергән экспертлар тикшергәннән соң, икенче турда катнашучылар гимназиянең официаль сайтына куела.

7.4. Икенче турга узган укучылар 24 нче февраль көнне Казан шәһәренең 14 нче гимназиясенә Конференциянең финалына чакырыла. Алар секцияләрдә чыгышлар ясый. Фәнни-эзләнү эшләренең кәгазь варианты чыгыш ясар алдыннан экспертлар комиссиясенә тапшырыла.

7.5. Экспертлар комиссиясе карары буенча иң яхшы тикшеренү эшләренең тезислары җыентыгы бастырылу планлаштырыла.

7.6. Конференциядә катнашу өчен заявка түбәндәге формада җибәрелә:

| Укучының фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы | Республика, шәһәр (район), мәктәп исеме (устав буенча), сыйныф | Телефон (мәктәп, өй яки кәрәзле телефон номеры) | Адрес, индекс | Фәнни җитәкченең фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, вазифасы | Кирәкле техник чаралар |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

## VIII. Конференцияне йомгаклау һәм нәтиҗә ясау

8.1. Жюри составына татар, рус һәм инглиз телләрен яхшы белгән, мәгариф һәм мәдәният өлкәсе белән якыннан таныш компетентлы белгечләр кертелә.

8.2. Жюри әгъзасының хокуклары:

укучыларның фәнни эшләренә, чыгышларына экспертлар комиссиясе (жюри) бәяләү критерийларыннан чыгып бәя бирә;

чыгышлар тыңланып беткәннән соң һәр секциядәге экспертлар комиссиясе нәтиҗә чыгара, җиңүчеләрне билгели;

карар беркетмәгә теркәлә, үзгәрешсез кабул ителә.

II турда катнашкан барлык укучыларга да Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының шаһәдәтнамәсе тапшырыла;

җиңүчеләр һәм призлы урыннарга ия булучылар Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының дипломнары белән бүләкләнә.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Лист согласования к документу № исх-3271/16 от 14.12.2016
Инициатор согласования: Зайнуллина Л. Р. Ведущий консультант отдела национального образования
Согласование инициировано: 12.12.2016 17:51

**Лист согласования** Тип согласования: **последовательное**

| N° | ФИО | Срок согласования | Результат согласования | Замечания |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Шарипова А.С. | | Согласовано 13.12.2016 - 09:21 | - |
| 2 | Исмагилова Г.Х. | | Согласовано 13.12.2016 - 09:27 | - |
| 3 | Мухаметов И.Р. | | Согласовано 13.12.2016 - 11:20 | - |
| 4 | Фаттахов Э.Н. | | Согласовано 13.12.2016 - 18:40 | - |